КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 16 сентябрь г.Казань № 1008

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 25 октябрь, 959 нчы карары белән расланган «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 25 октябрь, 959 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 10 ноябрь, 1005 нче; 2020 ел, 24 ноябрь, 1057 нче; 2021 ел, 25 ноябрь, 1118 нче; 2022 ел, 24 март, 267 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Төзүчеләр бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшкәндә өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча» сүзләрен «Территорияләрне үстерү фонды» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе тарафыннан «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе турында» Федераль законның $13^1$ статьясындагы 2 өлешендә каралган чараларны финанслау турында яки финанслау максатка ярашлы булмавы турында карар кабул итү кагыйдәләрен раслау хакында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары үз көчен югалткан дип тану хакында» 2019 елның 12 сентябрендәге 1192 номерлы карары белән (алга таба – Карар кабул итү кагыйдәләре) расланган «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе тарафыннан «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе турында» Федераль законның $13^1$ статьясындагы 2 өлешендә каралган чараларны финанслау турында яки финанслау максатка ярашлы булмавы турында карар кабул итү кагыйдәләре нигезендә Фонд тарафыннан Субсидия күчерелә торган датага финанслау турында карар кабул ителү;»;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Субсидия бирү нәтиҗәсе – түбәндәгеләр саны:

«Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе турында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның $9^1$ статьясындагы $2^1$ һәм $2^4$ өлешләре нигезендә Фонд тарафыннан яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Өлешле төзелештә катнашучы гражданнар хокукларын яклау фондын төзү турында» 2019 ел, 16 октябрь, 912 нче карары һәм «Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез мөлкәт объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге ФЗ-214 номерлы Федераль законның $21^1$ статьялары нигезендә төзелгән Татарстан Республикасының Өлешле төзелештә катнашучы гражданнар хокукларын яклау фонды – фондның оештыру-хокукый формасындагы коммерциягә карамаган унитар оешмасы тарафыннан, «Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез мөлкәт объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге ФЗ-214 номерлы Федераль законның $21^2$ статьясындагы 2 һәм 5 өлешләренә таянып, йорт төзүченең торак урыннарны, торак булмаган урыннарны, машина урыннарын тапшыру йөкләмәләре үтәлгән төзелештә катнашучылар;

Фонд яки әлеге коммерциягә карамаган унитар оешмасы тарафыннан «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның $13^3$ статьясындагы 3 өлеше нигезендә төзелешен тәгәлләү чаралары гамәлгә ашырылган күпфатирлы йортлардагы һәм (яки) башка күчемсез мөлкәт объектларындагы торак урынны, торак булмаган урынны, машина урыннарын тапшыру турында таләпләре булган торак-төзелеш кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы әгъзалары – гражданнары;

«Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә акчалары кире кайтарылган гражданнар.

Субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе һәм аңа ирешү срогы Килешүдә билгеләнә, аның бертип формасы Карар кабул итү кагыйдәләренең 2 нче кушымтасында бирелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин